КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1011

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасына 5 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт

программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 549 нчы; 2019 ел, 29 март, 239 нчы; 2019 ел, 13 сентябрь, 830 нчы; 2020 ел, 12 май, 380 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасына 5 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Муниципаль берәмлекләрне төзекләндерүнең комплекслы проектларын тормышка ашыру» юлының 4 графасында «Татарстан Республикасы территориясендә уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» дәүләт программасында каралган төзекләндерү чаралары гамәлгә ашырылды» (җиһазландырылган иҗтимагый киңлекләр саны), 2019 елдан башлап тупланып бара торган йомгак белән берәмлектән ким булмаган» сүзләрен «Заманча шәһәр мохите булдыруның дәүләт (муниципаль) программаларында каралган төзекләндерү чаралары тормышка ашырылды (җиһазландырылган иҗтимагый киңлекләр саны), 2019 елдан башлап тупланып бара торган йомгак белән берәмлектән ким булмаган» сүзләренә алыштырырга;

«Башка илкүләм һәм федераль проектлар чаралары белән төзекләндерү буенча башкарыла торган чараларны синхронлаштыру» юлының 4 – 12 графаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2018 елга карата шәһәр мохите сыйфатының уртача индексы арту, процент | - | - | 2 | 5 | 10 | 15 | 20 | 30 |
| Россия Федерациясе буенча шәһәр мохите сыйфаты индексының уртача мәгънәсе | - | 177 | 181 | 186 | 195 | 204 | 213 | 231 |
| Заманча шәһәр мохитенең дәүләт (муниципаль) программалары чараларын тормышка ашыру кысаларында сатып алынган җиһазларның гомуми күләмендә Россия чыгышлы җиһазларны, шул исәптән эшләрне башкарганда сатып алына торган җиһазларны сатып алулар күләме өлеше, процент | - | 88,2 | 88,2 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90»; |

«Кече шәһәрләрдә һәм тарихый җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохите булдыру буенча иң яхшы проектларның бөтенроссия конкурсында җиңүчеләр проектларын тормышка ашыру» юлында:

6 нчы графада «–» тамгасын «14» саннарына алыштырырга;

9 нчы графада «–» тамгасын «18» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин